Мордовиябездә торле татар авыллары яшәп килә - зурлары, кечкенәләре... Зурларында тормыш кайный, ә vлеп барган авыллырыбыз сvнеп килә. Әмма да бvген авылыбыз халкы тыныч һәм тату яши. Кон саен мәчет манарасыннан азан тавышы ишетелеп тора. Урамнарыбыз тәртиптә, кибетләр эшли, аларда жанын ни тели - барысы да бар. Ә кирәкле тозелеш материалларын китереп бирәләр - шалтырат кына.   Барыбыз да авылны ярата, мактый. Бер мизгел. Авыл. Жәй. Иртән кояш чыгып килгәндә, торып бакчана чыгуга сине ин беренче сандугачлар сайравы каршы ала. Бvтән кошларнын да уянып, бер-берсе белән хәбәрләшкән тавышлары ишетелеп тора. Офык читеннән кызарып чыгып килгән кояшны кvзәтv дә матур манзара. Бу монзара кvнелебнен ин тирән почмагында яши. Авылда авыр да, рәхәт тә яшәргә...
Ельник районы Лобановка авылында Халифә Кәрим кызы Бахтияровага житмеш, әмма тормыш энергиясе һәм оптимизм белән яши ул vз авылында. Бәлкем, югарыда сvрәтләгән авыл табигатен жvнләп кvрергә анын вакыты да аз кала торгандыр, чонки иртә ирсез кала, дvрт бала тәрбияли, олкән әти-әнисенә ярдәм итә, йорт хужалыгы да анын кулында була. Балалар vстерv һәм аларга тәбия бирv очен кvпме коч сарыф ителvен әниләребез белә инде. Ельник районы Лобановка авылында яшәvче Халифә Кәрим кызынын да тормыш тәжрибәсе зур булган әни. Балаларны тәрбияләvдән тыш, ул гомере буе колхозда эшләгән: сарыклар коткән, vгезләр, атлар караган. Кvптән инде пенсиядә, әмма элеккегечә анын ху-жалыгында дистәләгән кош-корт бар.
Х.К.Бахтиярованын сигез оныгы һәм бер оныкчыгы аны соендерәләр. Туган йортта, әниләре янында ботен зур гаилә булып бергә бик сирәк жыелалар. Язмыш аларны доньянын торле почмакларына тарата. Шуна да карамастан, Хәлифә Кәрим кызы балалары һәм оныклары килvен тvземсезлек белән котә. Улы Наиль гына Лобановка авылында яши. Ул - әнисенен барлык эшләрендә дә ышанычлы ярдәмчесе.

Тормышыбызда тагы бер кыш килеп жит-те. Кар явып vтте. Кvнелебезгә дә пакълык боркәнде, ә берничә конге томан, янгыр тагын кознен ямансу чагын искә тошерде. Әйтеп китәргә кирәк, кышнын беренче салкыннары башлану белән, Мордовия татарларыбызда бер бик матур ела – Каз омәләре vткәрv башлана. Анда бергә аралашу булсынмы, хәлдән тайганчы колдерә торган авыл такмаклары булсынмы... Ә тарихка кереп калган уеннарын искә алу – vзе бер кызык... Бvген каз омәләре артка калды; халык казларны кипятокка тыгып кына йолка. Омәләр оештырырга пандемия дә куркыта. Әле тагы ковиднын яна – “омикрон” штаммы билгеле булды…

Шунысы куанычлы: авылда кысынкылыкта яшәмисен, урамда саф һава сулап, чишмә-кое суы эчеп, сәламәтлегенне ныгытасын. Гаиләндәге тынычлык та эшкә дәрт ости, эшенне дә кvркәм итеп башкарасын. Шулай, Темников районы Татар Караевосындагы «Поздняков Шайхулла Шамилевич» КФХасы ат vрчетv производствасында унышларга ирешкән очен, «Агростартап» программасы буенча грант алды. Шәйхулла Шәмил улы турында газетабыз битләрендә еш укыйсыз. Татарларыбыз булдыклы, алар булдыралар.

Без барыбыз да авылдан чыккан кешеләр. Авыл ул безнен - vткәнебез, киләчәгебез, хәзергебез. Без бvген сезнен белән бергә шатланабыз: шәп учреждениеләр ачыла, авыл клубы һәм спорт залы - барысы бергә. Авылда тормыш шәһәрдәгедән начаррак булмаска тиеш. Шуна регионыбызда кvпләп максатчан программаларны гамәлгә ашырабыз; аларнын кvпчелеге авылга ярдәм итvгә, авыл кешеләренен тормышын яхшыртуга юнәлтелгән. Менә шулай Мордовиябезнен татар авыллларын яшәтергә тырышыбыз.

Наилә НАСЫРОВА